ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
ЗАИНСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЗӘЙ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

14.10.2021 г. Заинск № 616

**2022 елга “Зәй муниципаль районы” муниципаль берәмлеге гомуми белем бирү оешмалары укучыларын балаларны йөртү өчен махсус билгеләнгән автобусларда йөртүне оештыру буенча муниципаль хезмәт күрсәтү бәясе нормативларын раслау турында**

«Балаларны йөртү өчен махсус билгеләнгән автобусларда гомуми белем бирү оешмаларына укучыларны йөртүне оештыру нормативларын исәпләү буенча методик тәкъдимнәрне раслау турында» Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2010 елның 05 июлендәге 545 номерлы карарының 2 пункты нигезендә һәм Зәй муниципаль районы Уставының 45 статьясына таянып, Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районы Башкарма комитеты

**карар бирә:**

1. 2022 елга түбәндәге кушымталарны расларга:

2022 елга балаларны йөртү өчен махсус билгеләнгән автобусларда гомуми белем бирү оешмаларына укучыларны йөртүне оештыру буенча муниципаль хезмәт күрсәтү бәясе нормативларын (1 нче кушымта);

Балаларны йөртү өчен махсус билгеләнгән автобусларда гомуми белем бирү оешмаларына укучыларны йөртүне оештыру нормативларын исәпләү тәртибе турында нигезләмәне (2 нче кушымта).

2. «Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районы мәгариф идарәсе» муниципаль казна учреждениесенә түбәндәгеләрне тәэмин итәргә:

гомуми белем бирү оешмаларын әлеге карарның 1 пунктында расланган балаларны йөртү өчен махсус билгеләнгән автобусларда гомуми белем бирү оешмаларына укучыларны йөртүне оештыру буенча муниципаль хезмәт күрсәтү бәясе нормативлары нигезендә финанслауны.

3. Зәй муниципаль районы Башкарма комитетының оештыру бүлегенә әлеге карарны массакүләм мәгълүмат чараларында бастырып чыгарырга, Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми

порталында (http://pravo.tatarstan.ru) һәм Зәй муниципаль районының рәсми сайтында урнаштырырга.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Башкарма комитет җитәкчесенең социаль мәсьәләләр буенча урынбасары А.В.Чапковка йөкләргә.

**Башкарма комитет җитәкчесе** **Э.Э. Галеев**

Э.Р. Сәфәргалиев
3-27-42

Татарстан Республикасы
Зәй муниципаль районы
Башкарма комитетының
2021 елның 14.10.
616 номерлы карарына
1 нче кушымта

2022 елга балаларны йөртү өчен махсус билгеләнгән автобусларда гомуми белем бирү оешмаларына укучыларны йөртүне оештыру буенча муниципаль хезмәт күрсәтү бәясе нормативлары

| Автотранспорт чарасы моделенең исеме | Ике ставкалы норматив күләме | |
|---|---|---|
| | бер автотранспорт чарасына ставка, бер елга сумнарда | автотранспорт чарасы узган бер километрга ставка, сумнарда |
| КАВЗ | 154152 | 38,77 |
| ПАЗ | 153591 | 38,68 |
| ГАЗ «Газель» | 133242 | 31,16 |
| УАЗ | 132789 | 29,69 |
| FIAT | 136630 | 28,02 |
| Peugeot Boxer | 142063 | 27,66 |
| Ford Transit | 142320 | 31,34 |
| Камаз Марко-Поло3297 | 156063 | 36,63 |

**Эшләр идарәчесе** **Т.А. Лоптова**

Татарстан Республикасы
Зәй муниципаль районы
Башкарма комитетының
2021 елның 14. 10.
616 номерлы карарына
2 нче кушымта

Гомуми белем бирү оешмалары укучыларын балаларны йөртү өчен махсус билгеләнгән автобусларда йөртүне оештыру буенча муниципаль хезмәт күрсәтү бәясен исәпләү тәртибе турында
нигезләмә

1. Гомуми нигезләмәләр

1.1. Әлеге нигезләмә гомуми белем бирү оешмалары укучыларын балаларны йөртү өчен махсус билгеләнгән автобуслар белән йөртүне оештыру буенча муниципаль хезмәт күрсәтү (алга таба – муниципаль хезмәт) бәясен исәпләү механизмын билгели.

1.2. Муниципаль хезмәт күрсәтү бәясе муниципаль хезмәт күрсәтү бәясе нормативы, автотранспорт чаралары саны һәм хисап чорында автотранспорт чараларының факттагы йөреше нигезендә исәпләнә.

1.3. Муниципаль хезмәт күрсәтү бәясе нормативлары ел саен “Зәй муниципаль районы” муниципаль берәмлеге Башкарма комитеты тарафыннан раслана.

1.4. Муниципаль хезмәт күрсәтү бәясен формалаштырганда автотранспорт чараларының фактик йөреше турында мәгълүмат, автотранспорт чарасының расланган маршруты паспорты кысаларында автотранспорт чарасының хисап елында факттагы йөреше буларак, Татарстан Республикасында автотранспорт чараларының аерым төрләрен мониторинглауның бердәм системасы белешмәләре буенча кабул ителә.

2. Муниципаль хезмәт күрсәтү бәясен исәпләү

2.1. Муниципаль берәмлекнең муниципаль хезмәт күрсәтү бәясе түбәндәге формула буенча исәпләнә:

$$S_i = \sum_{m=1}^{k} (n_{f\,m} \times NF_{km_m} + NF_{as\,m} \times M_m),$$

монда:

$S_i$ – муниципаль хезмәт күрсәтү бәясе;

$n_{f\,m}$ - m модельле автотранспорт чараларының фактик йөгереше, километрларда;

$NF_{km_m}$ - гомуми белем бирү оешмалары укучыларын балаларны йөртү өчен махсус билгеләнгән автобусларда йөртүне оештыру буенча муниципаль хезмәт күрсәтү бәясе нормативы ставкасы, бер километрга, сумнарда;

$NF_{as\,m}$ - гомуми белем бирү оешмалары укучыларын балаларны йөртү өчен махсус билгеләнгән автобусларда йөртүне оештыру буенча муниципаль хезмәт күрсәтү бәясе нормативы ставкасы, бер автотранспорт чарасына, сумнарда;

$M_m$ - m моделенең автотранспорт чаралары саны, берәмлек;

$m$ - муниципаль берәмлектә кулланыла торган автобус моделе исеме;

$k$ - муниципаль берәмлектә кулланыла торган автобуслар саны.

**Эшләр идарәчесе** **Т.А. Лоптова**